№1, Сентябрь 2025

# Чишмә башы

МБГБУ “Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”

## Хәерле сәгатьтә!

Беренче сентябрьдә илнең барлык уку йортларында Белем көненә багышланган тантаналы линейка һәм Тынычлык дәресләре узды. Бу көнне чәчәк бәйләмнәре тоткан укучылар, укытучылар һәм эти-әниләр мәктәп алдына җыелды. Беренче сентябрь – яңа гына мәктәп тупсасын атлап керүче нәниләр өчен дә, чыгарылыш класс укучылары өчен дә иң дулкындыргыч вакыт. Чөнки мәктәп чоры – уку һәм дәресләр генә түгел, сыйныфташлар, дуслар белән аралашу мизгелләре дә ул.

Белем көненә багышланган тантаналы линейкада катнашкан кунаклар укучыларны яңа уку елы белән котлады, укуның шатлыклы һәм мавыктыргыч хезмәт булуын билгеләп үтте.

Барлык укучыларга һәм укытучыларга бу ел уңышлы һәм нәтиҗәле булсын!





## Бу санда:


- *1 нче Сентябрь – Белем бәйрәме*
- *Тынычлык дәресләре*
- *Терроризмга каршы көрәш көне*
- *Грамоталылык көне*
- *18 нче сентябрь – Г.Ахуновка 100 ел*
- *Укучылар иҗаты*


## Терроризмга каршы көрәш

Ел саен 3 нче сентябрь көнне Россиядә терроризмга каршы көрәштә бердәмлек көне билгеләп үтелә. Бу көн безнең йөрәкләрдә һәм аңнарыбызда мәңгегә калачак вакыйгаларга багышланган. Әлеге дата уңаеннан һәр класста әңгәмәләр үтте, барлык террор актлары корбаннарын, шулай ук хезмәт бурычын үтәгәндә һәлак булган хокук саклау органнары хезмәткәрләрен искә алдык, һәлак булганнарның гаиләләренә теләктәшлек белдердек.






**8 сентябрь** - Халыкара грамоталылык көне. Әлеге көннең төп максаты – укучыларның игътибарын грамоталылык проблемаларына җәлеп итү. Әлеге уңайдан мәктәбебезнең директор киңәшчесе укучылар белән “Мин-филолог” исемле уен үткәрде. Чарадан укучылар яхшы кәеф һәм уңай хис-кичерешләр алдылар.



## Көз ае - укучылар иҗатында

Табигатьтә алтын көз. Көз гаҗәеп матур, үзенчәлекле фасыл. Ул үзенең матурлыгы белән һәркемне таң калдыра. Агачларның матурлыгы, төсләргә бай булуы күз явын алырлык. Аларның нинди төстәгеләре генә юк: кызылы да, сарысы да, яшеле дә – барысы бар. Әйтерсең лә рәссам үз рәсеменә ялгыш кына буяу тамызган. Зифа, нечкә билле каеннар, нәзек усаклар алтынсу шәлләрен ябынганнар, ә миләш, кып – кызыл булып, кызыктырып тора. Өрәңге - үзенә бертөрле матур агач. Көзен өрәңгене яратам мин. Үзе генә дә ничә төсле. Агач яфракларыннан көзге букет ясап куюу – көзге символ булып тора. Көзен кипкән яфраклар да хуш исле, матур була. Табигатьтә көзнең сихри бер мизгеле...

**Әмирова Әминә, 6 нчы класс**

Җылы җәй узып киткәч, табигатькә алтын көз килә. Алтын көз агачларның, куакларның яфракларын сары, кызыл, көрән төсләргә мана. Урмандагы җәнлекләрнең эшләре арта, алар кышка әзерләнә башлыйлар. Һәрберсе өннәрен җылыта, азык әзерли. Керпе гөмбә киптерә, тиен чикләвек җыя, куян ак тунын кия. Күчмә кошлар җылы якларга китәргә әзерләнәләр.

Көз үзенең елак булуына карамастан, үзенчәлекле, юмарт чак. Уңышка бик тә бай. Күп кенә җиләк – җимеш көзен җитешә. Гөмбә җыю башлана. Гөмбәләр дә, әкияттәге төсле, юл кебек тезелгәннәр. Көзен фотоаппаратны кулымнан төшермим. Аның матурлыгын истә калдырасы килә. Әмма көз кыска шул. Көзнең бераз тагын да матур-матур пейзажлары белән сокланасы, көзге букетлар җыеп, табигатькә сокланып йөрисе килә.

**Минһаҗева Зәлия, 6 нчы класс**

## Истәлекле вакыйгалар



**Г. Ахунов** – күпьяклы, киңкырлы талант иясе. Ул – әдәбиятның алгы сафында торучы, тапкыр сүзле әдип. Төрле жанрларда иҗат иткән: хикәя, очерк, повесть, романнар язган; шигырьләр тудырган, тәрҗемә эше белән шөгыльләнгән. Әдәби тәнкыйть эшчәнлеген дә, драматургияне дә үз иткән. Күренекле якташыбызның тууына 100 ел уңаеннан укучылар әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты белән якыннан таныштылар, класс сәгатьләре, әңгәмәләр үтте.





Гариф Ахуновның дистәләгән романнары, повестьлары, очерклары, публицистик әсәрләре, исән чагында ук аны классик язучы буларак таныталар. Ул ярты гасырлык иҗади хезмәтендә татар һәм рус телләрендә 50 дән артык, шулай ук башка телләрдә китаплар бастырган.



18 нче сентябрь көнне Казанбаш мәктәбендә Г.Ахунов укулары үтте. “Хәзинә тапкан әдип” темасына фәнни-эзләнү эшләре юнәлешендә уңышлы чыгыш ясап, Миннеханова Гөлчәчәк 3 урынга, “Туган якка мәдхия” юнәлешендә Закирҗанова Әдилә 2 урынга лаек булдылар. Афәрин, кызлар!

**Сәхифәне әзерләде:** туган тел һәм әдәбият укытучысы Садриева Н.З.

**Редакция һәм нәшриятның адресы:** 422024, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 11нче йорт
**E- mail:** Sskor.Ars@tatar.ru

Социаль челтәр бите:
https://vk.com/77arsk_srkorsa